**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 150 минут**
**Максималь балл – 48 балл**

**I. Теоретик тестлар (10 балл).**

1. Читләтеп әйтүнең бер формасы, күренеш-хәлләрне, сыйфатларны предмет-сурәтләр белән атау (1 балл):
1) метафора
2) аллегория
3) символ

2. Җөмләдә сүзләрнең грамматик тәртибен үзгәртү, мәгънә басымы төшә торган сүзне алга күчереп кую (1 балл):
1) синтаксик фигура
2) инверсия
3) метафора

3. Лирик әсәрләр генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):
1) «Идегәй», «Ана догасы»
2) «Алсу», «Таһир-Зөһрә»
3) «Тәәссер», «Нәсыйхәт»

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):
1) М.Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә «Н» авылы
2) Ш.Камалның «Буранда» әсәрендә буран
3) Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәрендә хат

5. Әдәбиятның кешене хәрәкәттә, каршылыкларда күрсәтүгә, тормышның бер кечкенә өзеге аша кеше характерларын ачуга корылган төре (1 балл):
1) драматургия
2) проза
3) драма

6. Чәчмә әсәрләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Бер хәрабәдә», «Йөзек кашы», «Яз»
2) «Әйтелмәгән васыять», «Буранда», «Сүнгән йолдызлар»
3) «Йөзек кашы», «Буранда», «Искәндәр»

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Әсәрнең эмоциональ көйләнеше. Язучының фикерен җиткерү өчен сайланган хис яңгырашы. Ул әсәрнең идеясе, жанры белән дә бәйләнештә була. Героик, романтик, трагик, сатирик һ.б. төрләре бар*» (2 балл):

Җавап: _____________

8. Жанрларны лириклыктан эпиклыкка күчә бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) дастан
2) гражданлык лирикасы
3) хикәя

Җавап:_______

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (28 балл).

1. 1886 елның 1 гыйнварында Казанның Яңа бистәсендә туа. Мәдрәсәдә белем ала, мәдрәсә каршындагы рус классын уңышлы тәмамлый. Университетка керү хыялы белән яна. 1907 елда паралич сугып, гомерлеккә аяксыз кала. Кем турында сүз бара? (2 балл):

Җавап:_______

2. Ф.Әмирханның әсәрләре генә урын алган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Хәят», «Бер хәрабәдә»
2) «Бер хәрабәдә», «Буранда»
3) «Бер хәрабәдә», «Искәндәр»

3. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

*...Өрәк, Әсманың өрәге! Юк, бу сүз ялган! Бөтен дөнья халкы килеп, үз күзләре белән күргәнлекләрен сөйләсәләр дә, мин моңа ышанмыйм! И мәлгунь халык, ялганламагыз! Әсма өрәге – ул ни дигән сүз? Фәрештәләрдән өрәк чыгамы соң? Шул минем белән менә бу эскәмиядә утырып торган, бөдрә сары чәчле, зәңгәр күзле, фәрештә шикелле Әсмадан? Юк-юк, мин йөрәк яргыч итеп кычкырам, юк!..*

- *Ләгънәт сиңа, и тормыш! Әүвәл алдыйсың, аннан соң мыскыллыйсың!*

1) Фәрештәдән өрәк чыга алмый

2) Тормыш кешене алдауга, аннан соң мыскыллауга корылган

3) Тормышның мәгънәсе юк, Матурлык, Яшьлек, Мәхәббәт, Бәхет барысы да вакытлы

4. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәрендә Хикәяләүче, хәрабә һәм Фәхрия образларын төркемнәргә бүлеп языгыз (1 балл):

1) төп герой

2) символик образ

3) эпизодик герой

5. Ф.Әмирхан укыган мәдрәсә. Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) «Галия»

2) «Мөхәммәдия»

3) «Мотыйгия»

6. Ф.Әмирханның беренче әсәре кайсы елда дөнья күрә? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) 1886

2) 1907

3) 1926

7. Ф.Әмирхан әдәбиятның кайсы төрендә актив эшли? (2 балл):

Җавап:_______

8. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәре кайсы жанрга карый? (2 балл):

Җавап:_______

9. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

*...Аннан соң игътибарсыз гына, карамый гына, мине узып китте дә үзенең җеннәренә сөйләп барган сымак кыяфәт һәм әллә нинди төссез тавыш белән: - Күптән өйнең ул ягында кеше тормый. Анда бичура ияләнгән, - диде.*

*Бу сүз минем йөрәгемне туңдырып җибәрде.*

- *Мин белгән заманнарда анда фәрештәләр торалар иде.*

*Карчык мине әллә нинди сукмаклардан әйләндерде дә ярым җимерелгән бер ишек һәм паркетлары кырылган шакшы бер коридор аркылы биек түшәмле, зур-зур тәрәзәле бер бүлмәгә алып керде.*

Җавап:_______

10. Әлеге өзектә хикәяләүченең кичерешләрен ачу барышында Ф.Әмирхан нинди образлардан һәм алымнардан файдалана? (6 балл):

*...Әйе, кайчандыр бу агачта сандугачлар сайрый иде!*

*Бу хатирәләр минем күз алдымнан кадерле төшләр шикелле булып үтеп киттеләр. Бу эшләрнең булып-булмаганлыгын, бу эшләрне мин төшемдә генә күргәнме, әллә болар кайчандыр бервакыт өнемдә булып үткәннәрме икәнен аңлый алмый бераз утыргач, мин, ватык эскәмиядән торып, бакчаның урта бер җирендәге беседканы эзләргә керештем.*

*Кайчандыр бакчадагы хәятның мәркәзе булып торган бу беседка бу көн инде эченә керә алмаслык булып җимерелгән, кычытканнар белән чолганып утыра иде. Мин, аңа барып җитмәстән тукталып, пошынып, аның ишегенә карап тордым. Әгәр ул ишекнең теле булып та, кайчандыр үзе аркылы йөргән кешеләрнең, кайчандыр үзе аркылы аккан тормышның моңлы тарихын сөйләсә иде, мин, шөбһәсез, җиргә егылып елар идем.*

*Әле дә хәтеремдә: моннан биш ел элек бер кичне аның эчендә Фәхрия гитара уйнап утырган иде. Әсма белән без икәү, аңа күренми генә бер читтә торып, аның уйнаганын тыңлаган идек. Гитара Фәхриянең кулында елый, алтын тавышлы фәрештә елаган шикелле, моң һәм хәят катыш тавыш белән елый, һәм аның елашына Фәхриянең коңгырт күзләре, моңланып, хәяттан арыган шикелле хәлсезләнеп җавап бирәләр иде. Кем белә, бәлки, ул вакытта ук ул гитара һәм ул күз алдындагы бүгенге көнне күреп, бүгенге хәятсызлык, хәрабәлекне сизенеп моңланганнардыр. Ләкин Әсма белән мин, аны сизмичә, кичнең караңгысына кәефле чолганып, күз алдыбыздагы бу якты беседканы сөеп, күңелләребез белән иркәләп карап торган идек...*

11. Әлеге өзектә бакчаның үткәнен һәм хәзергесен янәшә куеп, язучы нинди фикерләр җиткерә? (6 балл)

**III. Иҗади бирем (10 балл).**

«Яманга юлдаш булсаң – бәла тагар, / Еланга ярдәм итсәң – кулың чагар» юлларына нигезләнеп, 10 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.